**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР                                ПОСТАНОВЛЕНИЕ

__________       ПГ-15 15.04.2025       №____

Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 27 октябрендәге ПГ-34 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 27 октябрендәге ПГ-34 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2 пунктындагы «г» пунктчасына «оешмалар» сүзләреннән соң, «цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2 өлешнең «г» пунктчасында , «акцияләрне» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Муниципаль район Башлыгы            Л.Р.Зарипов